ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» октябрь 2020 ел №337

«Суд тәртибендә хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган зат өстеннән опекун яисә попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 24 августындагы 265 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, тәңгәлсезлекләрне бетерү һәм аны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 11 декабрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Суд тәртибендә хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган зат өстеннән опекун яисә попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 24 августындагы 265 номерлы карарына 2 пунктны яңа редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«2. «Суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә яңа редакциядә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ яшьтәге затларга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 05 декабрендәге 489 номерлы карарының 1 өлешенең 1.2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе

муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **И.И. Шәмсетдинов**